When working on the 'Jömgha kön, kich belän…', particularly when translating the geographical names, Fatih Kutlu once again uses the method of transcription: Valparisa, Gallapogos, Titikaka, Kuala-Lumpur – shäp yangïrïy torgan isemnär, beläm! (Valparaiso, Galapagos, Titikaka, Kuala Lumpur – they all sound great, I know! (JKK: 210) / Valpariso, Galapagos, Titikaka, Kuala Lumpur; kulağa hoş gelen isimler, biliyorum! (CGA: 25). Ämma minem öchen Aqsïrghaq avïlï, Tashlïyar yelghasï tagïn da shäbräk yangghïrïy. (But for me the Aksirgak village, the Tashliyar River sound even better.) (JKK: 210) / Ama Aksırgak Köyü, Taşlıyar Çayı benim kulağıma daha hoş geliyor (CGA: 25). In this case the name Aksirgak is transcribed, and the word avïl (village) is translated to Turkish: köy. In another case we can see only the names: Karachuragha yeraqmï äle dip sorady. (He/she asked how far Karachuga was) (ÖAJ: 148) / Karaçura'ya daha çok mu diye sordu (BAT: 26) [Khabibullina, p. 60].

When translating the surnames, Fatih Kutlu 'keeps their Russian forms: Jihangir Säfärgalin – Cihangir Sefergalin, Gabrakhmanov – Ğabdrahmanov etc. Aqsïrghaqqa berenche tapqïr chittän kilgän predsedatel Jihangir Säfärgalin... (Chairman Jihangir Safargalin with his first time visit to Aksirgak...) (JKK: 211) / Aksırgak'a dışarıdan gelen ilk kolhoz yöneticsi Cihangir Sefergalin... (CGA: 27)'. Another interesting subject is the method of translating nicknames and bynames. Bua tavïshïn shul chaghïnda ayerïm achïq ishette Bibinur qarchïq (At that moment the old Bibinur heard the sound of the water (literally, pond) even more so clearly) (JKK: 211)/ Bibinur Kadın su bendinin sesini ilk kez net olarak o zaman duydu. (CGA: 33) [Khabibullina, p. 59].

A. Gilyazov, besides showing the national psychology of the characters, gives a detailed depiction of the Tatar life, customs, traditions and ethnography, which deepens the national spirit of the piece and creates a full picture of the Tatar nation. So, it naturally opens a way for introduction of notions that are peculiar only to the Tatar language. Truly, 'the names of items belonging to the material culture capture the real practical life of the nation. Nationality-specific vocabulary … gives an opportunity to discover differences and similarities between various ethnical cultures' [Nurmukhammatova, p. 34]. As the natural ethnocultural lexicon causes understandable challenges in translation work, it requires new methods for presenting these notions in Turkish.

In cases, where the words had no equivalents in Turkish, Fatih Kutlu uses the method of explanatory translation, particularly, in translation of names of the Tatar national clothing items: 'Kïz chaghïmnan kilgän ashyaulïqlarnï, tastïmallarïmnï, qashaghalarnï, türlämälärne, chikkän sölgeläremne, ayaqchularnï, palaslarnï, enjele qalfaghïma tiklem shunda iltep sattïm (I took and sold my table cloths I had back when I was a girl, my tastimals (embroidered tea towels), valances, turlama (wall valances), embroidered towels, ayakchu (leggings), rugs, even my pearl qalfaq (Tatar national

[1] F. Kutlu defines the genre of the given piece as a novel, however, in the Tatar literature theory it is considered as a short novel.

women's headdress)) (JKK: 312) / Ta benim kızlık zamanımdan kalan sofra örtülerini, işlemeli havluları, bördürleri, eskiden çorap yerine ayağımıza sardığımız ayakçuları, kilimleri, incili kalfağımı hepsini oraya götürüp sattım (CGA: 141). As noted by E. Khabibullina, the two national clothing item names, ayakchu (ayakçu) and qalfaq (kalfak) explain the lexical units transcribed from Tatar [Khabibullina, p. 64]. The translator uses the same method for translating the names of national holidays, customs and traditions: 'Äy, aulaq öygä baram digän ideng tügelme song?' ('Hey, haven't you said you were going to the aulak house (aulak – in the absence of the host, owner, parent)?' (JKK: 254) / 'Hey! Avlak üye gideceğim dememiş miydin?' (CGA: 76). 'Aqsïrghaqnïng ataqlï Saban tuyen mänggeläshterergä kilä!' ('I want to eternalize the famous Aksirgak Saban tuy!') (JKK: 342) / 'Aksırgak'ın meşhur Saban Toyu'nu ölümsüzleştirmek için geliyor!' (CGA: 178).

The scholar also includes the examples where the ethnocultural lexemes from the 'Cuma günü, akşam...' short novel related to the everyday life and ethnography of the Tatar people and that are absent in the Turkish culture are transcribed in the translation: 'Shikär sipkän döge bäleshen ülep yarata Bibinur, ber bashï ghïna bulghach, bäleshne sandugach oyasï khätle itep kenä pesherä' ('Bibinur dotes upon sugar coated rice balesh (Tatar pie), so much so she bakes it in the size of a nightingale's nest all for herself.') (JKK: 232) / Üzerine şeker serpilmiş pirinç belişini ne sever Bibinur. Bir başına olduğundan belişi bülbül yuvası kadarcık yapardı (CGA: 51). [Khabibullina, p. 63-64].

The Turkish translation of the short novel 'Jömgha kön, kich belän…' also includes different types of literary devices. Firstly, the reader sees the result of exact semantic translation. The translation shows how much F. Kutlu cares for the language of A. Gilyazov and how well he uses the authors' emotional and effective Tatar language expressions: the sentence *'Tau bashïnda bashaq isen sengdergän'* [Gilyazov, 1982: 84] is translated as '*Olgunlaşmaya yüz tutmuş başak kokusunu sindiren rüzgar'* [Giylecev, 2013: 33]. F. Kutlu drops the phrase *'tau bashïnda'('at the top of the hill')* and translats the word *'bashak' ('grain head')* with the phrase '*olgunlaşmaya yüz tutmuş başak' ('ready-to-harvest grain heads').* Whereasin the sentence *'Tegärjep avïlïna kübäläk kanatï kebek ütä kürenmäle janï ghïna iyärep kilgänder?' ('Maybe to the Tegarjep village came only his transparent, as a butterfly wing, soul?')* [Gilyazov, 1982: 86]the comparison *'kübäläk kanatï kebek' ('as a butterfly wing')* translated word by word – '*Tigercip Köyü'ne kelebek kanadı gibi şeffaf ruhu gelmiştir belki?'.* [Giylecev, 2013: 35]

Some of the tropes are translated with some changes to their components. For instance, in the sentence *'Dide dä, monglï küzlären tutïrïp qarap, tïnïp qaldï' ('He/she said that and went silent looking at him/her with those sad eyes')* [Gyilazhev, 1982: 80] the epithet '***monglï küzlären****' ('sad eyes') is translated as 'hüzün dolu gözlerini' ('eyes full of sorrow')* [Giylecev, 2013: 29], and in the sentence *'anïsï da küngel aqlïghïnnan äytelgän süzlär läbasa!' ('Surely, those words were said from the kindness of the heart!')* [Gyilazhev, 1982: 83]the metaphor *'küngel aqlïghï'* (literally, *'purity of the soul'*) is changed in translation into '*saygısındandı' ('with respect')* [Giylecev, 2013: 33]. While in the original the author describes the narrator's state of mind (*kindness of the heart*), the translator addresses his attitude towards another person (*with respect*). In the sentence *'Maqtansa da, küngel türendä qurqu bar ide' ('Even though he/she was bragging, atheart he/she was scared')* [Gyilazhev, 1982: 93]the metaphor '*küngel türendä' ('atheart')* was simply replaced with the word *'içinde' ('inside')* which does not deliver the precise meaning intended by A. Gilyazov [Giylecev, 2013: 43].

When translating the fixed phrases in the short novel, the translator uses the existing Turkish sayings to replace them. For instance, in the sentence *'Bibinurnïng küzläre* ***qïzïghïp yana, khätta avïzïna su kilä****, shulay da bireshmi' ('Bibinur's eyes began to sparkle, even her mouth started watering, but she still didn't give in')* [Gilyazov, 1982: 97] the fixed phrase is translated using an existing idiom:*'Görünce Bibinur'un* ***içi gider****, ağızının suyu akar, ama yine de belli etmezdi'* [Giylecev, 2013: 48].

There are some rare occasions where the tropes in 'Cuma günü, akşam...' ('Friday night...') are shortened or translated neutrally. For examples, in the sentence *'****Yazghï köläch avïllar*** *östenä kölep qaraghan al qoyash'('The red sun smiled down at the merry spring villages')* [Gilyazov, 1982: 80] the phrase ***'yazghï köläch avïllar'*** *('merry spring villages')* are simply translated as *'villages',* and the phrase *'kölep qaraghan al qoyash' ('smiling red sun')* as *'gülümseyen güneş' (smiling sun)* [Giylecev, 2013: 32]. In the unit *'beräm-beräm* ***avïr, sallïyoldïzlar*** *kabïndï' ('one by one lit up the heavy, bold stars')* [Gyilazhev, 1982: 87] the epi-

thets were dropped, and the phrase was translated only as 'yıldızlar' ('stars') [Giylecev, 2013: 37]. In our opinion, this method of translation diminishes the beauty of A. Gilyazov's poetry and does not allow the reader to see deeply into his thoughts.

However, the text of translation also includes cases where the adverbial clause is on the contrary put outside the sentence and given as a separate unit. In the sentence *'Qaranggï bulsa da, cherep uqmashqan salamnï ärsez jil irkenä birmichä, tübä östenä rät-rät tezeleshep yatkan kayen bastïrmalaral ayermachïk kürenep tora ide' ('Even though it was dark, the birch beams, laying on the roof in rows and protecting the decaying straw from the sly wind, were still clearly visible')* [Gilyazov, 1982: 77] the part *'cherep uqmashqan salamnï ärsez jil irkenä birmichä' ('protecting the decaying straw from the sly wind')* is translated as a separate sentence:*'Evin saman çöpleriyle örülü çatısını, keyfince esen rüzgar kendi haline bırakmıyordu.* ***Karanlık olmasına rağmen çatının üzerindeki sıra sıra huş gövdeleri farkedeliyordu****'*. [Giylecev, 2013: 25] *('Even though it was dark, the birch beams, laying on the roof in rows, were still clearly visible').* In some sentences, in order to make the phrases clearer for the Turkish readers, F. Kutlu uses the method of explanatory translation: 'Aqsïrghaq avïlïnïng … tönyaghïnda yuash taular tezmäse, tau östendä qara urman, urman artïnda yanga rayon bashlana'. [Gilyazov, 1982: 78] ('North from the Aksirgak village is a chain of peaceful mountains, at the top of the mountain is a black forest, behind of which starts a new district') // "Aksırgak Köyü'nün güneyinde *sıra sıra yayvan****(stretched out in rows)*** *tepeler*, tepelerde yeşil orman***(green forest)***, ormanın bitiminde iseyeni bir ilçe başlıyor" [Giylecev, 2013: 27]. Or: ***'Totïshïnnan*** *tirän* ***qayghï*** *kicherü börkelep tora ide. (His/her* ***demeanour*** *showed he/she was in* ***deep sorrow')*** [Gilyazov, 1982: 88]// Görünüşünden, tüm hal ve hareketlerinden ***(general state and movements)****derin bir kaygı* ***(deep sorrow)*** çağlıyordu. [Giylecev, 2013: 38] *'Bibinur vaq-vaq qïna yota-yota itle* ***ashnï da yaltïratïp quidï****'. ('Bibinur finished (*literally, *cleaned the plate) the meat stewin small bites')* [Gilyazov, 1982: 91] // 'Küçük lokmalarla ***etli yemeği***de bir güzel yedi.' [Giylecev, 2013: 41] F. Kutlu translated the word *'ash' ('soup')* as *'etli yemeği' (meat dishes).* But in this case the Turkish word 'çorba' which conforms to the meaning 'soup' would be undoubtedly a more adequate translation. The use of the phrase 'bir güzel yedi', or 'ate neatly, properly', to translate the phrase *'yaltïratïp quidï' (finished, cleaned the plate)* is also distorts the meaning of the sentence. While, on one hand, this approach of shortening the original sentences or completely omitting words or combination of words of the original in the translation text distorts the idea, feelings and different shades of the meaning that the author intended to get across, on the other hand, it diminishes the beauty of the language used in the original. Fortunately, there are not so many of such cases. In conclusion, it is fair to say that the Turkish translations of A. Gilyazov's works are generally well-executed, as they open up the Tatar world, lifestyle, national psychology to the Turkish audience. The fact that many of the Tatar sayings, literary tropes have their equivalents in Turkish proves how close our languages are and how many common spiritual and moral values we share.

As it is known, 'a literary translation exists in the target language literary context as a separate piece of literature and can be perceived and evaluated only in that context' [Toper, p. 65]. The work of F. Kutlu, which was chosen as a subject for this paper, reinforces the Tatar-Turkish culture, breaks the barriers between the two kindred nations and promotes the moral and lexicological exchange between them. F. Kutlu's literary translations popularize the national literature worldwide and celebrate its greatest aesthetic achievements, as well as introduce readers of other nationalities to the ethnical peculiarities, lifestyle and moral values of the Tatar people. And with that they renew and reinforce the possibilities of literary translations in general, which are considered one of the media of international interaction.

**References**

Abdullah Tukay. *Şiirler.* (2016). [Gabdulla Tuqai: Poems]. Translated by A. Akbash, F. Kutlu. 224 p. Ankara, "Bängü" Publishing House. (In Turkish)

Altın Sincap. (2014). [A Golden Squirrel: A Collection of Children's Stories]. Translated by F. Kutlu. 293 p. Ankara, "Bängü" Publishing House. (In Turkish)

Aristovich, P. A. (1984). *Sushnost' khudozhestvennogo perevoda: avtoref. dis. ... kand.* [The Essence of Literary Translation: Ph.D. Thesis Abstract]. Tbilisi, 25 p. (In Russian)

Beyaz Hırkalı İhtiyar. (2016). *Zəidulla R. "Ak iapanchaly kart"* [Zaidulla R. The Old Man in a White Coat]. Translated by F. Kutlu. 111 p. Ankara, "Bängü" Publishing House. (In Turkish)

Cengâver Alp'in Kahramanlıkları. (2013). *Batulla R. "Alyp batyr maҗaralary"* [Batulla R. The Adventures of Great Heroes]. Translated by F. Kutlu. 178 p. Ankara, "Bängü" Publishing House. (In Turkish)

Fildişi, Çakı. (2013). *“Səiak saply pəke”: Balalar khikəialəre җyentygy* [A Penknife with a Bone Handle: A Collection of Children’s Stories]. Translated by F. Kutlu. 168 p. Ankara, “Bängü” Publishing House. (In Turkish)

Ganieva, R. K. *Tvorchestvo Gabdully Tukaia v kontekste mirovoi literatury* [The Works of Gabdulla Tuqai in the Context of World Literature] Gabdulla Tuqai Web-site. URL: http://gabdullatukay.ru/news/gabdulla-tukaj-v-kontekste-mirovoj-literatury/ (In Russian)

Ganieva, R. K. (2002). *Shagyir'neң rukhi dən'iasy* [A Poet’s Soul (materials prepared for an encyclopaedic publication about Gabdulla Tukay)]. 112 p. Kazan, TaRIKH. (In Tatar)

Gilyazov, A. (1982). *Jomgha kön, kich belän…* [Friday Night… Short Novels]. 360 p. Kazan, Tatar Publishing House. (In Tatar)

Ğıylecev, A. (2013). *Cuma günü, akşam…* [Gyilazhev A. Friday Night…]. Translated by F. Kutlu. 202 p. Ankara, “Bängü” Publishing House. (In Turkish)

Gyilazhev, A. (2002). *Sailanma əsərlər* [Selected Works. In Five Volumes]. Volume I. 431p. Kazan, Tatar Publishing House. (In Tatar)

Ğıylecev, A. (2013). *Bir Avuç Toprak* [Three Arshins of Land]. Translated by F. Kutlu. 113 p. Ankara, “Bängü” Publishing House. (In Turkish)

*“Izge esh bashkaru – yze bəkhet”* [“Working for a great cause is happiness in itself”]. An Interview of L. Galimzhanova with F. Kutlu. Shahri Kazan. URL: http://www.sptatar.ru/index.php?option=com_k2&view=item&id=310:фатих-кутлу-“изге-эш-башкару-үзе-бәхет”&lang=tt. (In Tatar)

Khabibullina, E. K. (2016). *Yazyikovyie transformatsii pri perevode tatarskoy literaturyi na turetskiy yazyik: dis. ... kand. filol. nauk.* [LinguisticTransformations in Translations of Tatar literature to Turkish: Ph.D. Thesis]. 283 p. Kazan, KFU. (In Russian)

Khannanov, R. (2011). *Tərek-tatar ədəbi baglanyshlary* [Turkish-Tatar Literary Interrelations]. Kazan utlary. No. 2, pp.78–83. (In Tatar)

Kharrasova, R. (2002). *Ədəbi bəilәneshlər iaktylygynda* [In the Light of Literary Interrelations]. 138 p.Kazan: ‘RPF “Gart”. (In Tatar)

Kuprelezada (Muhammad Fuat). (2009). *Gabdulla Tukaev* [Gabdulla Tukaev]. Translated from Turkish by N. Vakhitov. Kazan utlary. No. 4, pp. 115 –124. (In Tatar)

Khabutdinova M. M. *From the History of A. Gilyazov’s “On Friday Evening…”* (1979). Filologiia i kul'tura. Philology and Culture. 2012. №3(29) (2012). C.156-164.

Mallaliev, G. N. (2006). *Problemy hudozhestvennogo perevoda poezii (na materiale poeticheskih tekstov russkoi i tabasaranskoi literatur): avtoref. diss.* [Problems of Literary Translation of Poetry (based on the materials of poetic texts from the Russian and Tabasaran literature: Ph.D. Thesis Abstract]. Makhachkala, 24 p. (In Russian)

Mavi, Hüzün (2007). *“Zəңgər sagysh”:Razil Vəliev shigyr'ləre* [Blue Sorrow: Razil Valiev’s Poetry]. Translated by F. Kutlu, H. Tashkyn. 144 p. Istanbul: “Da” Publishing House. (In Turkish)

Minnegulov, Kh.Yu. (2008). *Tatarga da tylmach kirək* [Tatars Also Need Translators]. Madani jomgha [Cultural Friday]. 10 October. (In Tatar)

Mukhammatov, I. R. (2007). *Tatar-tərek ədəbi baglanyshlarynda Məkhəmməd Chələbineң "Məkhəmmədiia" kitaby* [The Book by Mukhammad Chalabi ‘Mukhammadiya’ in the Context of the Tatar-Turkish Literary Relations]. 136 p.Kazan : Sh. Marjani Institute of History. (In Tatar)

Nagimov, N. I. (2006). *Perevodyi Sagita Suncheleya iz zapadnoevropeyskoy literaturyi: avtoref. diss.* [West-European Literature: Translations of Sagit Suncheley: Ph.D. Thesis Abstract]. Kazan, 23 p. (In Russian)

Nurmukhammetova, R. S. (2016). *Tatar teleneң etnomədəniiat leksikasy* [Tatar Ethnocultural Vocabulary]. TATARICA. No.1 (6), pp. 34–42. (In Tatar)

Rakhman, Rifa. (2002). *Tərek-tatar ədəbi bəiləneshlərenең kaiber səkhifələre* [A Few Pages of the Turkish-Tatar Literary Ties]. Kazan utlary. No. 7, pp. 66–72. (In Tatar)

Rakhmanov, Z. A. (1991). *Problemyi hudozhestvennogo perevoda i literaturnyih svyazei: avtoref. diss.* [Problems of Fictional Translation and Literary Connections: Ph.D. Thesis Abstract]. Dushanbe, 24 p. (In Russian)

Saifullina, F. S. (2014). *Tatarsko-turetskie kulturnyie i nauchnyie vzaimosvyazi: istoriya i sovremennost* [On Tatar-Turkish Cultural and Scientific Interactions: Past and Present]. Philology and Culture. No.2 (36), pp. 322–326. (In Russian)

Safina, G. F. (2014). *Lirika A.S. Pushkina v perevodah na tatarskiy yazyik: istoriya i poetika: avtoref. diss* [Lyric Poetry of A.S. Pushkin in Translationsinto Tatar: History and Poetics: Ph. D. Thesis Abstract]. Kazan, 23 p. (In Russian)

Sessiz, Kuray (2013). *Tavyshsyz kurai: povest' həm khikəialər җyentygy* [The Mute Qurai: AShort Novel and Collection of Stories]. Translated by F. Kutlu. 190 p.Ankara: “Bängü” Publishing House. (In Turkish)

*Tərek matbugatynda “Өch arshyn җir” turynda basylyp chykkan ədəbi tənkyit' məkaləlǝre* [Literary Critical Reviews of ‘Öch arsh'in jir’ in the Turkish Media] // URL: http://www.sptatar.ru/index.php?option=com_k2&view=item&id=314:төрек-матбугатында-“өч-аршын-җир”-турында-басылып-чыккан-әдәби-тәнкыйть-мәкаләләре&lang=tt (accessed: 12.06.2017). (In Turkish)

Toper, P. (1998). *Perevod i literatura: tvorcheskaya lichnost perevodchika* [Translation and Literature: A Creative Personality of a Translator]. Voprosy literatury. No.6, pp. 61–65. (In Russian)

Vasiyet / *“Vasyiyat”: povest həm khikəialər җyentygy* (2012) [“Vasiyet” / The Last Will: A Novella and Collection of Short Stories]. Translated by F. Kutlu,

H. Arsoy-Nadir, T. Arslan. 111 p. Istanbul: “Zambak” Publishing House. (In Tatar)

# ФАТИХ КУТЛУ ТӘРҖЕМӘЧЕ ҺӘМ ТӨРКИЯДӘ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫН ТАНЫТУЧЫ БУЛАРАК

**Флера Сәгыйт кызы Сәйфулина,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан ш., Кремль ур., 18 нче йорт,
fsaifulina@mail.ru.

**Альбина Зинфир кызы Вәлиева,**
“Икътисад югары мәктәбе” Милли тикшеренү университеты,
Россия, 101000, Мәскәү, Мясницкая ур., 20 нче йорт,
fsaifulina@mail.ru.

Мәкаләнең башлам өлешендә татар-төрек багланышларының өйрәнелү һәм XXI гасыр башында татар китапларының төрек теленә тәрҗемә ителү тарихына кыскача күзәтү ясала. 1985 елгы үзгәртеп коруларга кадәр суынып торган бәйләнешләрне җанландыруга зур өлеш керткән Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, тәрҗемәче һәм филолог Фатих Кутлуның тәрҗемәчелек эшчәнлеге һәм аның татар әдәбиятын Төркиядә танытудагы хезмәте өйрәнелә. Ф. Кутлу, тәрҗемәче буларак, милли сүз сәнгатенең төрле чорларына караган күренекле әдипләрнең әсәрләренә мөрәҗәгать итә. Ул татар классиклары Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, Ш. Камал, Ә. Еники, шулай ук хәзерге чор язучылары Р. Вәлиев, М. Галиев, Г. Гыйльманов, Р. Зәйдулла һәм башкалар иҗаты белән төрек укучыларын таныштырды.

Күренекле прозаик һәм драматург А. Гыйләҗев аның тәрҗемәләре арасында аерым урын тота. Тәрҗемәчене XX гасыр татар әдәбиятының кыйммәтле сәхифәләреннән берсе булган язучы мирасында кешенең катлаулы рухи дөньясы, милли сыйфатлары, инде мәңгелеккә китеп баручы авыл кешесе күңел кичерешләренең сәнгати яктан гәүдәләнеше кызыксындыра. А.Гыйләҗевнең Фатих Кутлу (Fatih Kutlu) тарафыннан төрек теленә тәрҗемә ителгән «Өч аршын җир» («Bir avuç toprak») һәм «Җомга көн, кич белән...» («Cuma günü, akşam...») әсәрләре мәкаләнең тикшерү материалы булып тора. Шушы уңайдан хезмәттә тәрҗемәчелекнең аерым аспектлары, Ф. Кутлуның тәрҗемә өлкәсендәге осталыгы, үзенчәлекләре һәм алымнары бәяләнә.

**Төп төшенчәләр**: Татар әдәбияты, төрек-татар әдәби бәйләнешләре, әдәби мирас, мәдәният, татар язучылары, Аяз Гыйләҗев, әдәби тәрҗемә, Фатих Кутлу (Fatih Kutlu), тел-сурәтләү чаралары.

Тәрҗемә төрле халыкларның аралашуына, аңлашуына, рухи хәзинәләр алмашуына хезмәт итә. Фән-техника, мәдәният дөнья күләмендә югары үсеш алган хәзерге заманда тәрҗемәнең әһәмияте гаять зур. Аның роле бүген бөтен дөнья буйлап җәелә барган глобальләшү шартларында тагын да арта төшә. Тәрҗемә – чыганак телдән алынган билгеле бер мәгълүматны икенче телгә җиткерүне үз эченә алган интеллектуаль эшчәнлек. Тәрҗемәчедән, беренче чиратта, ике телне дә төгәл белү, әдәби-эстетик тоем, зәвык сорала.

Башка телләргә тәрҗемә ителү аша әдәби әсәрләре белән башка халыкларны таныштыру һәр язучыны кызыксындыра. Әдәби тәрҗемәләр әдәбиятлар алмашынуга, халыкларның берберсен тануына, рухи-әхлакый аңлашуга, мәдәни диалогка юллар ача. Әдәбият галиме Х. Миңнегулов тәрҗемә эшенең гаять киңкырлы һәм әһәмиятле функция башкаруына басым ясый: «Тәрҗемә – гадәти лингвистик яки әдәби күренеш кенә түгел, ә үзара аңлашуның, рухи, мәгълүмати байлыклар белән танышуның гаять мөһим чарасы да. Ул кешеләрне, халыкларны, илләрне, чорларны якынайта, аларның үзара сөхбәт-диалогларын тәэмин итә» [Миңнегулов, 2010: 10 октябрь].

Әдәби тәрҗемә мәсьәләсе XX гасыр башыннан ук актуальләшә һәм әдәбият галимнәре тарафыннан игътибар үзәгенә алына. Бу юнәлештә фәнни хезмәтләрнең шактый язылуы да әдәби тәрҗемә мәсьәләсенең башка

халыклар әдәбиятлары өчен дә актуаль булуын дәлилли ([Аристович, 1984: 25]; [Рахманов, 1991: 24]; [Маллалиев, 2006: 24]; [Нагимов, 2006: 23]; [Сафина, 2014: 23]).

XIX гасыр ахыры – XX йөз башы чикләрендә татар-төрек багланышлары гадәти кабул ителә, әлеге чорда төрки халыклар арасында мәдәни-әдәби багланышларның нык булуы хакында мәгълүматлар күп ([Рахман Рифә, 2002: 66-72]; [Харрасова, 2002: 138]; [Мөхәммәтов, 2007: 135]; [Ханнанов, 2011: 78-83]).

Билгеле булганча, совет чорында әлеге кардәш халыклар арасында мөнәсәбәтләр шактый суынды, бәйләнешләр күп елларга тукталды. Бары тик XX гасыр ахырында, илебездә барган зур үзгәрешләр нәтиҗәсендә әлеге бәйләнешләрне әкренләп җайга салу, тергезү мөмкинлеге туды. Соңгы чирек гасыр эчендәге үзгәрешләр төрек-татар багланышларының да ныгуына китерде; бу, үз чиратында, дистәләрчә еллар дәвамында әдәби багланышларның ерагаюы, кардәш халыкларның бер-берсенең әдәбиятлары, мәдәни үсеше хакында хәбәрдарсызлыгын да танырга этәргеч ясады. Төрки телле халыклар әдәбиятларын тугандаш халыклар теленә тәрҗемә итү мәсьәләсенең актуаль булуы хакында фикер ТЮРКСОЙ оешмасының Генераль директоры Дусен Касеновның төрки телле халыкларның әдәби журналлары мөхәррирләренең II Конгрессында (2008) ясаган чыгышында да ачык яңгырады.

Әлеге юнәлештәге хезмәттәшлек татар китап укучыларын кардәш халыкларның күренекле әдәби әсәрләре белән таныштыру, шулай ук татар әдәбиятын төрки милләтләр мохитендә таныту өчен дә зур мөмкинлекләр бирәчәк. Соңгы елларда татар язучылары әсәрләренең төрек теленә тәрҗемә ителүе, аерым җыентыклар рәвешендә Төркиядә дөнья күрүе – әлеге юнәлештәге эшнең тернәкләнеп китүен раслый.

Бүгенге көндә Төркиядә үз милли әдәбиятларын дөньяга таныту юнәлешендә җитди эш алып барыла. Махсус проект нигезендә соңгы 7 елда төрек әдәбияты әсәрләре 41 телгә тәрҗемә ителгән, 50 илдә 750гә якын китап басылып чыккан. Шунысы куанычлы: бүгенге көндә бу эш ике яклы булып, татар теленнән төрек теленә тәрҗемә итү дә шактый популярлашып бара. Әлеге уңай үзгәрешләр тугандаш халыкларның мәдәни-әдәби якынаюы нәтиҗәсендә генә мөмкин булды [Сәйфулина, 2014: 322-326].

2005 еллардан башлап татар әдәбияты әсәрләре төрек теленә тәрҗемә ителеп, Төркиядә дөнья күрә башлады. Әлеге әсәрләр исемлегендә беренчеләрдән булып татар әдәбиятының кече эпик әсәрләренең тәрҗемәләрен туплаган «Vasiyet» («Васыять») җыентыгы игътибарга лаек. «Замбак» нәшриятында 2005, 2006 һәм 2012 елларда аның өч басмасы дөнья күрә [Vasiyet, 2012]. Китап аңа кергән әсәрләр исемлеген дә тәрҗемәгә тәкъдим иткән галим Хатыйп Миңнегуловның кереш сүзе белән ачыла. Җыентыкка тупланган әсәрләр – Фатих Кутлу, Хәмзә Әрсой, Надир Тамәр Арслан тарафыннан тәрҗемә ителгән. Аңа татар хикәяләреннән иң матур үрнәкләр – Әмирхан Еникинең «Әйтелмәгән васыять», «Матурлык», Шәриф Камалның «Буранда», «Уяну», Фатих Әмирханның «Бер харәбәдә», «Сәмигулла абзый», Галимҗан Ибраһимовның «Табигать балалары», Мирсәй Әмирнең «Мөстәкыйм карт йокысы», Фатих Хөснинең «Сөйләнмәгән хикәя», Миргазиян Юнысның «Безнең өй өянкеләр астында иде» кертелгән. Р. Вәлиев әсәрләреннән тупланган «Mavi hüzün» («Зәңгәр сагыш») китабының Төркиянең «Da» нәшриятында 2007 елда дөнья күрүе әлеге башлангычның уңай дәвамы буларак бәяләнергә хаклы [Mavi Hüzün, 2007]. Җыентыкны тәрҗемә итүчеләр – Фатих Кутлу, Харун Тосуннар. Ф. Кутлу тәрҗемәсендә «Fildişi Çakı (Tatar çocuk hikayeleri)» (“Балалар өчен язылган татар хикәяләре”) [Fildişi Çakı, 2013], “Sessiz Kuray” (“Тавышсыз курай”) [Sessiz Kuray, 2013] исемле повесть һәм хикәяләр җыентыгы “Бәнгү” нәшриятында басылып чыкты. Аның тарафыннан Р. Батулла әкиятләре [Cengâver Alp’in Kahramanlıkları, 2013], балалар өчен “Altın Sincap” (“Алтын тиен”) [Altın Sincap, 2014] хикәяләр җынтыгы тәрҗемә ителеп төрек укучыларына барып ирешә. Соңгысында Н. Думави, А. Алиш, Г. Рәхим, Д. Аппакова, Л. Ихсанова, Ф. Вәлиев, Ф. Әмирхан һ.б. язучыларның әсәрләре урын алган. Тәрҗемәче көче белән Р. Зәйдулланың «Ак япанчалы карт» әсәре дә Төркия китаплар киштәсендә урын алды [Beyaz Hırkalı İhtiyar, 2016].

Шунысы игътибарга лаек: Төркия Мәгариф министрлыгы тарафыннан балалар мәҗбүри укырга тиешле расланган йөз китап арасында Ф. Кутлу тәрҗемә иткән Ә. Еникинең «Әйтелмәгән васыять» һәм «Матурлык»

хикәяләре дә кертелгән [Фатих Кутлу: “Изге эш башкару – үзе бәхет”]. Әлеге факт, бер яктан, тәрҗемәченең талантын бәяләү булса, икенчедән, татар әдәбияты үрнәкләренең төрек дөньясында да таныла башлавын раслый.

Шул рәвешле, Ф. Кутлуның тәрҗемәче буларак игътибарын татар әдәбиятының төрле әдәби-тарихи чорлары кызыксындыра. Ул тәрҗемә иткән әсәрләр арасында XX гасыр башы татар поэзиясе һәм прозасы (Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Ш. Камал), Бөек Ватан сугышы еллары татар прозасы (А.Алиш), XX гасырның икенче яртысы прозасы һәм поэзиясе (Ф. Хөсни, А. Гыйләҗев, Р. Вәлиев), бүгенге татар әдәбияты (Р. Батулла, Р. Зәйдулла) үрнәкләре дә бар. Ф. Кутлуның тәрҗемә эшчәнлегендәге башка тәрҗемәчеләрдән аерылып торган киң диапазонлылык сыйфаты аның татар әдәби барышын тирән белүен һәм аңлавын күрсәтә.

Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Ф. Кутлуны татар әдәбиятын төрек теленә тәрҗемәче буларак таныткан хезмәте – Габдулла Тукай шигырьләрен тәрҗемә итү өлкәсендә булды. Моңа кадәр татар халык шагыйренең бу күләмдә төрек теленә әле тәрҗемә ителгәне юк иде. Ф. Кутлу каләмдәше А. Акбаш бәй белән бу җаваплы эшне 10 ай дәвамында башкаралар. Милли шагыйребезнең 130 еллык юбилее уңаеннан 130 әсәре шагыйрь һәм язучы Р. Зәйдулла ярдәме белән сайлана. 1917 ел инкыйлабына кадәр Төркия вакытлы матбугатында Г.Тукай әсәрләре вакыт-вакыт басыла килә. һәм менә, ниһаять, 100 елдан соң Тукай яңадан Төркиягә кайтты. [Abdullah Tukay, 2016] Шигърият сөючеләргә, әдәбият белгечләренә, язучы-шагыйрьләргә милли һәм халыкчан шагыйрь иҗаты белән киңрәк планда танышуга, аны яңача бәяләүгә юллар ачылды. Тукай төрек галимнәре тарафыннан кыска гына вакыт эчендә «рус һәм алман романтиклары дәрәҗәсенә күтәрелә алган» романтик шагыйрь буларак күзаллана иде (Ф. Күпрелезадә, А. Тимер) [Ганиева, 2002]. Хәзерге тәрҗемәләр, Г.Тукайны милли реалист-шагыйрь буларак ачып, төрек укучыларына аның шигъриятенең асылын, тамырларын, аның эстетик карашларының киңлеген, поэтик мирасының күпкырлылыгын аңларга мөмкинлек бирә. Тәрҗемәче, тарихи чынбарлыкны исәпкә алу аша шагыйрьнең әдәби образлары дөньясына тирән үтеп кереп, татар халкының традицияләрен һәм сәнгати фикерләү үзенчәлекләрен күрсәтүгә ирешкән. Әлеге билгеләр тәрҗемәләрнең югары кимәлдә эшләнүен тагын бер кат раслый.

Фатих Кутлу, алга таба тагын да катлаулырак әсәрләргә алынып, аның уңай башлангычы А. Гыйләҗев әсәрләрен тәрҗемә итү юнәлешендә дәвам итте. Аның тарафыннан язучының «Өч аршын җир» («Bir avuç toprak») [Ğıylecev A. Bir Avuç Toprak, 2008; 2011], «Җомга көн, кич белән...» («Cuma günü, akşam...») [Ğıylecev A. Cuma günü, akşam…, 2013] тәрҗемә ителеп, Төркиядә дөнья күрде.

Ф. Кутлу Төркиядә Аяз Гыйләҗев иҗатын танытуга зур өлеш кертә. Тәрҗемәченең язучы белән беренче тапкыр танышуы аның әсәре аша булып, әлеге хакта ул китапның кереш өлешендә бәян итә. Кибет киштәсендә аның игътибарын «Йәгез, бер дога» исемле саллы әсәре җәлеп итә. Авторын ачыклагач, китапны сатып алып, зур кызыксыну белән тәфсилләп укый. «Бу романны укыганда, Аяз Гыйләҗевнең сынаулар тулы тормышы белән таныштым һәм аңа булган хөрмәтем тагын да артты; үземнең соклануны белдереп, «Заман-Татарстан»га хат җибәрдем һәм 2000 нче елның апрель аенда Аяз Гыйләҗев белән шәхсән күрешү бәхетенә ирештем.

Имза куйдырту нияте белән «Йәгез, бер дога!» китабын да үзем белән алган идем. Аяз бәйнең китапка миңа атап язган җөмләсе аңа булган соклануымны тагын да арттырды: «Фатих бәй, сез минем өемә кояшның бер кисәген алып килдегез, рәхмәт!» – дип язган иде Аяз бәй. Икенче көнне Аяз бәй мине кабат өенә чакырды, тарих профессоры, улы Искәндәр һәм драматург улы Мансур абыйлар белән таныштырды. Хикәяләр һәм романнары тупланган 4 томлык китабына: «Мөхтәрәм Фатих бәйгә – гаҗәеп төрек баласына чиксез яратып, зур өметләр баглап бүләк итәм шушы китапларны» дигән автограф язып тәкъдим итте. «Сезгә бу китапларны бүләк итмә[1], кабул итәрсезме?» – дип сорады. «Күктән ни яуган да, җир кабул итмәгән?» – дидем мин» [Kutlu, 2013: 3].

Очрашудагы әңгәмә вакытында Ф. Кутлу автордан: “Кайсы әсәрегезнең төрек теленә тәрҗемә ителүен теләр идегез?” – дип сорый. А. Гыйләҗәв, ике дә уйлап тормыйча: “Өч аршын җир”не”, – дип җавап бирә. Язучы вафат булганнан соң, Ф. Кутлу әлеге теләкне язучының васыяте буларак кабул итеп, повестьны төрек теленә тәрҗемә итә башлый.

[1] “Бүләк итмә” гыйбарәсе бүләк ителгән, бүләк буларак мәгънәсендә.

Әүвәл ул әсәрне, татар телендәге үзенә таныш булмаган сүзләрнең астына сыза-сыза, сүзлекләргә мөрәҗәгать итеп, дүрт тапкыр укып чыгуы хакында яза, тәрҗемә өстендә ике ел буена эшли: «Укый-укый әсәрнең теленә, рухына, кешенең үз эчке дөньясын кулга ала белү сәләтенә хәйран калдым. Әсәрне бер тапкыр гына уку җитми, кабат-кабат сеңдерә-сеңдерә уку кирәк. Укыганда, җөмләдәге һәр сүз нечкә итеп үрелгәнен аңладым. Заман үтү белән, әсәрнең искермәячәгенә ышанам» [Fatih Kutlu, 2013: 5].

Тәрҗемәченең әсәр өстендә эш процессын тәфсилләп бәян итүе – катлаулы тәрҗемә эшенә җитди якын килеп, әсәрнең телен, бөтен рухын тирән аңлап эш итәргә кирәклекне тагын бер кат искәртә. Бу хакта Ф. Кутлу «А. Гыйләҗевнең әсәрләрен су кебек эчмичә, башка татар язучыларының әсәрләрен укымаска, татарча язма һәм сөйләм телемне аның әсәрләре ярдәмендә үстерергә дә карар бирдем. Төрки телләр бер-берсенә никадәр якын кебек күренсә дә, әдәби әсәрне тәрҗемә итү җиңел эшләрдән түгел. Татар әдәбиятында шәһәр әдәбияты юк булып, авыл әдәбияты бардыр. Шәһәрләрдә төрле тел һәм мәдәниятка караган милләтләр берлектә яшәгәнгә күрә, милли һәм дини төсләрне авыллар саклап калган. Татар халкының шагыйрь һәм язучылары гына түгел, әдәби әсәр геройлары да авылныкы. Безнең әдәбиятта авылдан булганнарны «көйле» дип кенә әйтсәләр (köy – төрекчә «авыл»), татарларда «köy insanı», ягъни «авыл кешесе» дип әйтәләр. Бу сәбәпле, безнең татар әдәбиятыннан аласы әйберләребез күп булса, татар халкының да бездән – шәһәр әдәбиятыннан аласы әйберләре бар” [Fatih Kutlu, 2013: 7],– дип яза. Әлеге китапка кереш сүзен тәрҗемәче түбәндәге сүзләр белән тәмамлый: «Аяз бәйнең кабере янына әсәрне тәрҗемә итеп бетергәч кенә барырга карар бирдем. Китабын алып: «Миңа татар әдәбиятына мәхәббәт уяткан, аның гүзәллекләре белән таныштырган, газиз остазым, тыныч йокла! Теләгең җиренә килде!» [Fatih Kutlu, 2013: 8]. – дидем.

Шул рәвешле, повесть төрек телендә «Bir avuç toprak» дигән үзенчәлекле исем белән дөнья күрә. Әдәбият белгече П. Топер карашынча, «әдәби әсәрне укып кабул итүче фикере – әлеге тәрҗемә уңышлымы, яки юкмы булуы хакында бәхәсләрдә төп аргумент булып тора. Чөнки нәкъ менә укучы фикере (тәнкыйтьче дә әсәрне укучы) үзе тирәсендә тәрҗемәне бәяләү өчен кирәк булган, теленең вак кына детальләренә кадәр туры килүе хакында барлык критерийларны туплый, чөнки, ахыр чиктә, тел күренешләре сүзлекләрдән түгел, ә замана кулланучыларының “тере” сөйләше аша кабул ителә» (тәрҗ. безнеке. – *Ф.С.)* [Топер, 1998: 61].

Төрек укучылары тарафыннан «Өч аршын җир» повесте югары бәяләнеп, ул Ч. Айтматовның «И дольше века длится день» («Елдан озын көн») романы белән бер дәрәҗәдә кабул ителә. 2012 елда А. Гыйләҗев әсәренең тәрҗемәсе Ауразия Язучылар берлегенең төрки телләрдән төрекчәгә иң яхшы тәрҗемә әсәре буларак җиңү яулый. Әсәргә язылган дистәләгән бәяләмәләр шул хакта сөйли.

Язучы Назмия Данизер укучыларда туган җиргә мәхәббәт, һәр инсанның туган җире һәм ата-анасы каршындагы бурычы турында искә төшерүгә юнәлтелгән геройларның психологик характеристикасын бирүдә авторның осталыгын ассызыклый. Аның фикеренчә, әсәрнең геройлар тормышын тарихи барыш кысаларында ачуга юнәлтелгән фабуласы уңышлы сайланган. Мәкалә авторы әсәрнең киң яңгыраш алу сәбәбен аның вакыйгаларны бәян итү стилендә күрә. Төрек язучысы татар әдибенең интрига тудыру осталыгын да билгеләп үтә: Аяз Гыйләҗев сюжет линиясен үстерүдә ретроспектив алымын файдалана. Н. Данизер тарафыннан әсәр вакыйгаларының тыгыз үрелгән һәм бөтенлекле итеп оештырылуы төгәл күрсәтелә.

«Өч аршын җир» повестен укыгач, Таһир Танер А.Гыйләҗевне «татар Стендале» дип атый. Аны әсәрнең проблематикасы, татар язучысының фәлсәфи фикерләү киңлеге сокландыра. Әдәбият белгече Бәтүл Җошкун үзенең рецензиясендә повестьның проблематикасы юнан трагедияләре традициясендә дип билгели. Төрек язучысында әсәрдә тудырылган төп герой, А. Гыйләҗевнең конфликтларны кору осталыгы зур кызыксыну уята. Бәтүл Җошкун фикеренчә, СССР да коллектив хуҗалык төзү вакытында хосусый милек ияләренең, шәхеснең хокуклары бозылган. Мирвәли авылдашлары кылган эшләр өчен рәнҗешне кичерә алмый, шул сәбәпле үзен һәм хатынын гомерлеккә читтә каңгырып йөрүгә, кайгы-хәсрәткә дучар итә.

Икенче бер төрек шагыйре Календер Йолдыз А. Гыйләҗев әсәрләрен Ч. Айтматов әсәрләре белән чагыштырып, «Өч аршын җир» повестеның роман эчтәлеге потенциалына ия

булуын билгеләп үтә. Аның игътибарын «Өч аршын җир» повестенда һәм «Елдан озын көн» («И дольше века длится день») романында язучыларның фольклор материалын файдалану осталыгы тарта [Төрек матбугатында «Өч аршын җир» турында басылып чыккан әдәби тәнкыйть мәкаләләре].

2016 елда Истанбул университетында Абдулкадир Чәкич «Аяз Гыйләҗев әсәрләрендә культура көрәше» темасына кандидатлык диссертациясен яклый.

Шул рәвешле, Аяз Гыйләҗев әсәрләре төрек аудиториясендә дә үз укучысын тапты һәм галимнәр тарафыннан фәнни әйләнешкә кертелде. Бүгенге көндә Төрек университетларында татар прозаигы әсәрләре буенча магистрлык диссертацияләренең язылуы тагын да куандыра. Әлбәттә, әлеге юнәлештәге хәрәкәтнең башында Ф. Кутлуның тәрҗемә өлкәсендәге уңышлы эшчәнлеге тора. Нәкъ аның тәрҗемәләре аша татар язучысы әсәрләре төрекчә яңгыраш алды.

Әлбәттә, әдәби әсәр тәрҗемәсенең уңышы тәрҗемәнең оригиналга якынлыгыннан гына тормый. Бу очракта тәрҗемә ителгән әсәрнең эстетик кыйммәте дә әһәмияткә ия, һәм әлеге очракта якынлык төшенчәсе бөтенләй икенче мәгънәгә ия була башлый. Топер билгеләгәнчә, «тәрҗемә, беренчедән, әдәби әсәр, икенчедән, башка телдә яңадан тудырылган әдәби әсәр буларак икеләтә шартлылыкка ия. Шул исәптән сюжет хәрәкәте тирәсендәге реальлеккә мөнәсәбәт кенә түгел, ә геройларның эчке дөньясы кебек нечкә катлам, милли холыклар һәм милли фикер йөртү үзенчәлеге дә. Шуна күрә тәрҗемә – сәнгать әсәренең аерым төре, шулай булгач, тәрҗемәче дә үзенең сәнгате белән ике мәдәният кисешендәге чиктәш җирдә яшәүче һәм иҗаты белән бары тик укучыга гына юнәлтелгән үзенчәлекле художник. Тәрҗемәче таланты дигәндә, әлеге сюжетны яңача яңгырату, үз шартларында (ягъни, автордагыдан башка шартларда) оригиналдыгы кебек үк тәэсир тудыру осталыгы карала» [Топер, 1998: 64].

Повестька төрек теленә тәрҗемәдә, алда ассызыкланганча, үзенчәлекле исем бирелә. Фатих Кутлу тарафыннан тәкъдим ителгән «Bir avuç toprak» («Бер уч туфрак») атамасы фикри-мәгънәви һәм милли-мәдәни эчтәлеге белән повестьның оригинал исеменә аваздаш. Төрек телендә «Бер уч туфрак» «газиз ватан туфрагы, кабер, үлем» дигән тирән фәлсәфи мәгънәле фразеологик гыйбарә, идиома булып тора. «Üç arşın yer» («Өч аршын җир») атамасының сүзгә-сүз тәрҗемәсе төрек укучысына гади сүзләр тезмәсе буларак кына яңгырый. Әсәрнең оригиналын һәм тәрҗемә вариантын чагыштырма планда өйрәнү Фатих Кутлуның төрек һәм татар телләрен камил белүен күрсәтә.

Образлылык тудыру – әдәби әсәрнең иң әһәмиятле ягы һәм ул әдәби әсәрдә тел-сурәтләү чаралары ярдәмендә тормышка ашырыла. Тәрҗемә эшендә күчерелмә мәгънәдә кулланылган гыйбарәләр – тропларны тәрҗемә итү кыенлык тудыра. Аларда халыкның менталитеты, тормыш фәлсәфәсе, гасырлар буенча тупланып килгән көнитеш тәҗрибәсе чагылыш табу сәбәпле, тәрҗемәчегә халыкның тарихы, фәлсәфәсе, яшәү рәвешеннән дә хәбәрдар булу кирәк.

Төрек һәм татар телләре уртак төрки телләр гаиләсенә караганлыктан, аларда сүзләрнең фразеологик бәйләнешендә, образлылык системасында, һичшиксез, уртак яклар да, кыпчак һәм угыз телләр группасына керү аркасында, үзенчәлекләр дә бар. Болар халыкларның тормыш-көнкүреше, яшәеше, сәнгатьчә фикерләве, табигать, җәмгыять күренешләрен күзаллавы белән дә бәйле. Бертөрле фәлсәфи караш, сәнгатьчә фикерләү нәтиҗәсе буларак, ике телдә дә мәгънәләре һәм образлары бертөрле булган сурәтләү чаралары күзәтелә.

Шул ук вакытта һәр телнең үзенә генә хас образлылык чаралары да булуы мәгълүм. Мондый лексик сурәтләү чараларын исә турыдан-туры тәрҗемә итү мөмкин булмаганлыктан, тәрҗемәче эмоциональлегә, эстетик тәэсир итү көче белән оригиналга тиң булырлык сурәтләү чараларына мөрәҗәгать итәргә тиеш була. Әмма төп нөсхәнең милли колоритын, үзенчәлеген, авторның индивидуаль стилен саклау зарури.

Фразеологизмнар, мәкаль-әйтемнәр кебек, 4 ысул белән тәрҗемә ителә. Иң активларының берсе – сүзгә-сүз, ягъни калькалаштырып, яисә компонентларның берсен үзгәртеп тәрҗемә итү. Тропларның образлылыкларын саклап тәрҗемә итү, билгеле булганча, оригиналның мәгънәви һәм сәнгати кыйммәтен тулы итеп бирүдә әһәмиятле юл булып тора. Төрек һәм татар халкының сәнгатьле фикерләвендәге уртаклыкларның зур булуы да моңа ярдәм итә. Моннан тыш, нәзари фикерләрдән күренгәнчә, тәрҗемәчедән әдәби әсәрдәге беренчел һәм икенчел образлылыктагы (туры һәм күчерелмә

мәгънәдәге) тел-сурәтләү чараларын сайлауда саклык белән эш итү сорала.

Ф.Кутлуның оригинал һәм тәрҗемә телләрнең әдәби формаларыннан тыш, халыкның җанлы сөйләм телен, диалектларын, телнең күп нечкәлекләрен нечкә тоемлап эш иткәне аңлашыла. Тәрҗемә теле дөрес, әдәби нормаларга туры килгән, оригиналдагыча җанлы, бай һәм эмоциональ тәэсирле.

Фатих Кутлу әсәрдәге әдәби тропларны төрле ысуллар ярдәмендә тәрҗемә иткән. Мисал өчен, «*Ул тәмле төшләр күрә-күрә, изелеп, үз урынында йоклап ята иде*» [Гыйләҗев, 2002: 191] җөмләсендә «*тәмле төшләр*» эпитетын төгәл «*tatlı rüyalar*» тәрҗемәсе аша бирә [Ğıylecev, 2013: 14]. Төгәл тәрҗемә ысулы бу әсәрне төрекчәгә тәрҗемәдә бик киң файдаланыла. «*Шул чагында Мирвәлинең каты, калын тавышы и шетелде*» [Гыйләҗев, 2002: 192] җөмләсендәге «*каты, калын тавышы*» эпитеты «*sert ve kalın sesi*» дип төгәл тәрҗемә ителә [Ğıylecev, 2013: 16]. «*Фельдшер хатын поездның нәкъ койрыгында – унөченче вагонда Сочига бер айлык ялга китеп бара иде*» [Гыйләҗев, 2002: 191] җөмләсендә «*поездның нәкъ койрыгында*» метафорасы шулай ук сүзгә-сүз тәрҗемә ителүе белән игътибарны үзенә тарта – «*trenin tam kuyruğunda*» [Ğıylecev, 2013: 14].

Әсәрдә тропларның аерым компонентларын үзгәртеп тәрҗемә итү юлы да шактый еш очрый. Мисалга, «*Мирвәлинең күзләре утлы күмер кебек яна иде*» [Гыйләҗев, 2002: 193] җөмләсендә ***«утлы күмер кебек яна иде*»** чагыштыруы «*Mirveli'nin gözleri* ***ateş saçıyordu***» (***ут чәчә иде***) дип, төрек кешесе өчен ятышлырак гыйбарә аша тәрҗемә ителгән [Ğıylecev, 2013: 17]. Аерым очракта ул икенче мәгънәдә дә кулланылган: «Фельдшер авыруның *дымлы,* ***кайнар учын*** *үз кулына* алды» [Гыйләҗев, 2002: 194] җөмләсенең тәрҗемәсе түбәндәгечә тәкъдим ителгән: «Sağlık memuru hastanın *nemli,* ***ateş gibi yanan (ут кебек янган)*** *avucunu elleri arasına* ***(куллары арасына)*** aldı» [Ğıylecev, 2013: 19].

Тәрҗемәдә тропларны кыскартып тәрҗемә итү, кайбер очракларда киресенчә, киңәйтеп, аңлатма рәвешендә бирү ысулы да кулланылган. «*Аңа бер җылы сүз генә кирәк*» җөмләсендә «***җылы сүз***» эпитеты «*içini ısıtacak güzel bir söz*» (***эчен җылытачак матур бер сүз***) [Ğıylecev, 2013: 94] дип тәрҗемә ителгән. Шуның белән бергә, ***güzel*** *(гүзәл)* төрек кәлимәсенең татар теленең күпсанлы мәгънә төсмерләрен бирүдә кулланылуы күзгә ташлана. Бер очракта *«****җылы сүз****»* - «***güzel bir söz****»* буларак тәрҗемә ителсә, икенчесендә «***купшы наратлар****» («****güzelim naratlar****»)* әлеге сүз белән бирелгән.

Бер тропның әдәби әсәрдә төрле гыйбарәләр ярдәмендә тәрҗемә ителешендә, һичшиксез, аның әдәби-эстетик вазифасы да зур роль уйный. Психологизм остасы буларак танылган А. Гыйләҗев, үз героеның күңел кичерешләрен тирән ачу теләге белән тропларга еш мөрәҗәгать итә, ә Ф.Кутлу әдипнең әлеге стиль үзенчәлеген нечкә тоемлый һәм мәгънәләре шактый якын булган тропларын төрле вариацияләрен, тәрҗемәнең төрле ысулларын сайлый. Текстта «***җылы сүз***» гыйбарәсенең төрлечә тәрҗемә ителүе шул хакта сөйли: «Авылдашың Мирвәлигә бер генә дә ***җылы сүзең*** юкмыни? [Гыйләҗев, 2002: 250] // «Köylün Mirveli'yi ***tатлı edecek (күңеле булырдай)*** *bir kelimen* de mi yok?» [Ğıylecev, 2013: 94]; яки икенче бер очракта, «Син менә ***йомшак сүз*** ишетмичә, ***җылы караш*** тоймыйча ирекле адәм баласының күпме яши алуын санап кара! ? [Гыйләҗев, 2002: 250] // Sen *tatlı bir söz* ***(татлы бер сүз)*** işitmeden *samimi* ***(самими)*** *bir bakış* görmeden insan oğlunun ne kadar yaşayabileceğini bir hesapla!» [Ğıylecev, 2013: 94] – «***йомшак сүз***» гыйбарәсенең дә «***tatlı bir söz****» (татлы бер сүз)* буларак тәрҗемә ителүе күзәтелә. «Аңа бер ***җылы сүз*** генә кирәк» – очрагында « ***içini ısıtacak güzel bir(эчен җылытырлык матур бер)*** *söze* ihtiyacı var» дип тәрҗемә ителгән [Ğıylecev, 2013: 94]. Әлеге җөмләдә «*җылы сүз кирәк*» фразасының «***söze ihtiyacı var» (сүзгә ихтыяҗы бар)*** дип тәрҗемә ителүе төрек теленең шактый «йомшак» булуын күрсәтә. Икенче бер очракта «***җылы караш***»ның «*samimi* ***(самими караш)*** *bir bakış»* дигән тәрҗемәсе безнең фикерне ныгыта [Ğıylecev, 2013: 94]. Кешеләр арасындагы уңай һәм матур мөнәсәбәтләрне ачуда да тәрҗемәче («*җылы җепләр бәйли»* [Гыйләҗев, 2002: 251] - *«samimi* ***(самими)*** *bağla* bağlıyormuş» [Ğıylecev, 2013: 95] *самими* сүзен куллана.

Фатих Кутлу сурәтләү чараларының төрек телендә эквивалентлары табылганда, синонимнарга да мөрәҗәгать итә. Текстта *«тәмле»* сүзенең «*tatli*» кәлимәсе белән төгәл, ә *«йомшак җил»* очрагында «*йомшак*» сүзенең дә (*«****tatlı*** *bir rüzgar» tatlı* дип тәрҗемә ителүе төрек телендә *güzel* һәм *tatlı* сүзләренең мәгънәви яктан

киңлеге һәм кулланылыш ешлыгы белән аңлатыла.

Тәрҗемәченең фразеологик әйтелмәләрне, төрекчәдә булып, төрек укучысына төгәлрәк аңлашыла торган әзер әйтелмә белән алыштырган очраклары да бар: *«Күңел капкасын ачып, кешеләргә үзен күрсәтергә яратмый иде Мирвәли»* [Гыйләҗев, 2002: 298] җөмләсендәге «*күңел капкасын ачу*» – «*эчке дөньясын ачу*» рәвешендә тәкъдим ителгән (*«İnsanlara iç dünyasını açtayı sevmıyordu Mirveli»)* [Ğıylecev, 2013: 24].

А.Гыйләҗевнең “Өч аршын җир” повестенда вакыйгалар хронотобы, яисә әсәр каһарманнарының эчке кичерешләрен ачуга хезмәт иткән табигать күренешләре җәенке, аерым очракларда күп компонентлы җөмләләр белән тасвирлана. Фатих Кутлу тарафыннан, язучының әдәби стиле сакланып, шактый катлаулы җөмлә структураларының да мәгънәви яктан төгәл һәм камил тәрҗемә ителүе соклану уята: «Зиратта койма буенда күпереп утырган баллы бабай чәчәкләре өстендә *алтын суы йөгерткән* төклетуралар, бал кортлары оча» [Гыйләҗев, 2002: 248] // «Mezarlık çitinin kenarlarındaki yoncaların üzerinde *altın suyuna boyanmış* ***(алтын суга буялган)*** yaban arıları, bal arıları *vız vız* uçuşuyor». [Ğıylecev, 2013: 90]. «*Кояштан оялып керфекләрен йома торган* бу гаҗәеп чәчәкләр әле ачылып бетмәгәннәр» [Гыйләҗев, 2002: 251] // «*Güneşten utanarak kirpiklerini yuman* bu harika çiçekler daha tam açmamışlar» [Ğıylecev, 2013: 94]. «Аның куерып кушылган кашлары хәрәкәтләнделәр, аз гына бөдрәләнеп торган ап-ак чигә сакалларына *ут капкан кебек* сыек зәңгәр төтен белән капланды» [Гыйләҗев, 2002: 192] // «İç içe girmiş koyu kaşları oynadı, hafif kıvırcık bembeyaz sakalını *sanki alev almış gibi* açık mavi bir duman kapladı» [Ğıylecev, 2013: 16]. «*Сөймәсә, аның белән авылны ташлап, җиде ят җирләргә чыгып олагыр идеме?!*» [Гыйләҗев, 2002: 221] // «*Sevmeseydi, onunla köyü terk edip yedi kat yabanci yerlere geder kaybolur muydu*» һ.б. [Ğıylecev, 2013: 56]. Болар тәрҗемәченең әсәр мәгънәви тукымасын тирән һәм нечкә тоемлавын, һәр сүз-сурәткә йөкләнгән вазифага сизгерлеген тагын бер кат дәлилли.

Җентекле чагыштырма анализ, сүзләр яки гыйбарәләрнең тәрҗемә ителмичә, нейтральләштереп бирелгән очракларының аз булуын күрсәтә. Мәсәлән, *«Усал, әрсез үлемне көрәшеп кенә җиңеп була!»* [Гыйләҗев, 2002: 206] җөмләсендә *«әрсез үлем»* эпитеты тәрҗемә ителмичә калган, ләкин мондый мисаллар күп түгел [Ğıylecev, 2013: 34].

Тропларның төрле чаралар һәм ысуллар ярдәмендә тәрҗемә ителеше әсәрнең милли колоритын, рухын саклап калырга ярдәм итә. “Өч аршын җир” повесте төрек теленә тәрҗемәсендә дә эстетик гүзәллеген югалтмаган. Әдәби текстларда телләрнең сыгылмалылыгы, фикер, хис-тойгыларны мөмкин булган кадәр төгәл җиткерү омтылышы әлеге фикергә этәрә. Әдәби әсәр эчтәлегенә хилафлык килмәү тәрҗемәченең тел сурәтләү чараларының төрек укучысына якынрак булганнарын сайлау осталыгына да барып тоташа. Бик сирәк очракларда гына аерым сүзләрнең мәгънәсе тәрҗемәче тарафыннан төгәл бирелмәгәнлеге күзәтелә. Мисал өчен, «*Бригадир аптырап тирә-якташыларга карады, нидер әйтергә теләгәндәй тәрәзәгә, тәрәзә артында бер-берсен кочаклашып авып калган агачларга ымлады*» [Гыйләҗев, 2002: 195] җөмләсендә «*тәрәзә артында бер-берсен кочаклашып авып калган агачларга*» тезмәсе «*trenden düşerek geride kalan iki tomruğu gösterdi*» (*поезддан төшкәндә артта калган ике бүрәнәне күрсәтте*) дип тәрҗемә ителгән [Ğıylecev, 2013: 20].

Ф.Кутлу эшчәнлеге, әдәби әсәр теле үзенчәлекләренә нисбәтле, тәрҗемә ысулларының байлыгы белән характерлана. Э. Хәбибуллина карашынча, «татар һәм төрек телләрендә исемнәр нигездә тәңгәл киләләр. Беренче чиратта, бу уртак тамырлар белән аңлатыла». Ф. Кутлу ялгызлык исемнәрен тәрҗемә иткәндә, трансформацияләү өчен транскрипция алымын файдалана. «Ирнең исеме Мирвәли иде» (ӨАҖ: 139) / Adamın adı Mirveli’ydi (BAT: 17); Нинди Шәмсегаян? (ӨАҖ: 139) / Ne Şemsigayan’ı? (BAT: 17). Мисаллардан күренгәнчә, әсәр геройлары Мирвәли, Шәмсегаян исемнәре тәрҗемәдә транскрипция аша бирелә» [Хабибуллина, с. 59].

«Өч аршын җир» повестен тәрҗемә иткәннән соң гына, Ф. Кутлу А. Гыйләҗевнең икенче – фәлсәфи, катлаулы эчтәлекле «Җомга көн, кич белән...» повестен тәрҗемә итәргә алына. «Cuma günü, akşam...» исеме белән 2013 елда дөнья күргән китапның «Тәрҗемәче сүзе» (Çevirmen sözü) өлешендә тәрҗемәче Фатих Кутлу тарафыннан укучыларга кызыклы мәгълүмат бирелә. «Әсәрне 2005 елда укыганда, романның төп герое Бибинур мине бик тетрәндерде. Шул вакыт башымда романны

тәрҗемә итү фикере туды. Әсәрнең күләме «Өч аршын җир»дән ике тапкыр зуррак иде. «Җомга көн, кич белән...» романы[2] рус теленә тәрҗемә ителгәннән соң, Аяз Гыйләҗевкә Максим Горький исемендәге дәүләт премиясе бирелде. Бу әсәрдәге язучының рухын, әдәби көчен, мәгънәсен никадәр бирә алганыбызны белмим. ... Иншаллаһ, бер көн бу эшнең гүзәл тәрҗемәләрен ясарлар. Бу эшчәнлек тә шул көнгә кадәр бер эшкә ярарлык булыр дип өметләнәбез. Аяз Гыйләҗевне таныткан һәм «Җомга көн, кич белән...» әсәрен яхшырак аңлау өчен аның язмаларын укыганым өчен, аеруча, Миләүшә ханым Хәбетдиновага зур рәхмәтемне әйтәсем килә. Сөенечкә, «Җомга көн, кич белән» («Cuma günü, akşam...») әсәре Аяз Гыйләҗевнең 80 еллык юбилеена һәм «Өч аршын җир» («Bir avuç toprak») әсәре 85 еллык юбилеена җитеште» [Giylecev, 2013: 7].

А. Гыйләҗевнең «Җомга көн, кич белән...» (1979) повесте – тәнкыйтьчеләр тарафыннан төрлечә бәяләнгән катлаулы әсәрләрнең берсе [Хабутдинова]. Повесть татар авылының үткәне, бүгенгесе, буыннар арасында бәйләнешләр өзелү, туган нигезне оныту, яшь буынның әхлаксызлыгы кебек мәсьәләләрне күтәрә. А. Гыйләҗев исемен татар әдәбияты тарихында гына түгел, дөнья мәдәниятендә дә таныткан « «Җомга көн, кич белән...» әсәре өчен авторга 1983 елда Г. Тукай исемендәге дәүләт премиясе бирелә. «Җомга көн, кич белән...» – совет җәмгыятенә, илгә 1930 елларда идеология алып килгән тәртипләргә тирән бәя бирүче әсәр» [Giylecev, 2013: 10].

Фатих Кутлу «Җомга көн, кич белән...» повесте өстендә эшләгәндә, аеруча топонимнар һәм гидронимнарны тәрҗемә иткәндә, яңа транскрипция алымына мөрәҗәгать итә: Вальпариса, Галлапогос, Титикака, Куала-Лумпур – шәп яңгырый торган исемнәр, беләм! (ҖКК: 210) / Valpariso, Galapagos, Titikaka, Kuala Lumpur; kulağa hoş gelen isimler, biliyorum! (CGA: 25). Әмма минем өчен Аксыргак авылы, Ташлыяр елгасы тагын да шәбрәк яңгырый (ҖКК: 210) / Ama Aksırgak Köyü, Taşlıyar Çayı benim kulağıma daha hoş geliyor (CGA: 25). Бу очракта Аксыргак исеме транскрипцияләнеп, авыл сүзе –төрек теленә тәрҗемә ителгән: köy. Икенче урында бары тик исемнәрне генә күрәбез: Карачурага еракмы әле дип сорады (ӨАҖ: 148) / Karaçura'ya daha çok mu diye sordu (BAT: 26) [Хабибуллина, с. 60].

Фамилияләрне тәрҗемә иткәндә, Фатих Кутлу «рус теленә хас булган форманы саклый: Җиһангир Сәфәргалин – Cihangir Sefergalin, Габдрахманов – Ğabdrahmanov h.б. Аксыргакка беренче тапкыр читтән килгән председатель Җиһангир Сәфәргалин... (ҖКК: 211) / Aksırgak'a dışarıdan gelen ilk kolhoz yöneticsi Cihangir Sefergalin... (CGA: 27)». Кушамат яки тәхәллүс белән бирелгән ялгызлык исемнәрен тәрҗемә итү ысулы кызыксыну уята. Буа тавышын шул чагында аерым ачык ишетте Бибинур карчык (ҖКК: 211) / Bibinur Kadın su bendinin sesini ilk kez net olarak o zaman duydu. (CGA: 33)» [Хабибуллина, с. 59].

А.Гыйләҗев, геройларның милли психологиясен ачудан тыш, әсәренең милли рухын тирәнәйтү, татар халкының милли дөнья сурәтен тудыру максаты белән, аның үзенчәлекле көнитешен, гореф-гадәтләрен, этнографиясен җентекләп тасвирлый. Ә алар әдәби әсәрнең лексик катламына бары тик татар теленә генә хас булган төшенчәләрнең килеп керүенә юл ача. Чыннан да, «матди мәдәниятне белдергән предмет атамаларында халыкның тормыш тәҗрибәсе чагылыш таба. Милли тамгалы лексика ... төрле этник мәдәнитләрнең үзенчәлекле һәм гомуми якларын табарга мөмкинлек бирә» [Нурмөхәммәтова, 2016: 34]. Табигый, этномәдәни лексика тәрҗемә эшендә билгеле бер кыенлыклар тудырып, аларны төрек телендә бирүдә яңа алымнар эзләнүләргә этәрә.

Ф.Кутлу эквиваленты булмаган лексиканы тәрҗемә итү очракларында, аңлатма бирү ысулына мөрәҗәгать итә. Бу аеруча милли татар киемнәре атамаларын тәрҗемә итү вакытында күзәтелә: «Кыз чагымнан килгән ашъяулыкларны, тастымалларымны, кашагаларны, түрләмәләрне, чиккән сөлгеләремне, аякчуларны, паласларны, энҗеле калфагыма тиклем шунда илтеп саттым (ҖКК: 312) / Ta benim kızlık zamanımdan kalan sofra örtülerini, işlemeli havluları, bördürleri, eskiden çorap yerine ayağımıza sardığımız ayakçuları, kilimleri, incili kalfağımı hepsini oraya götürüp sattım (CGA: 141). Э.Хәбибуллина билгеләгәнчә, бу җөмләдәге ике милли кием атамасы – аякчу (ayakçu) һәм калфак (kalfak) транскрипция аша бирелгән лексемаларга аңлатма бирә [Хабибуллина, с. 64]. Милли бәйрәмнәрне һәм гореф-гадәтләрне тәрҗемә иткәндә дә, тәрҗемәче шул ук ысулны файдалана: «Әй, аулак өйгә барам дигән идең түгелме соң?» (ҖКК: 254) / Hey! Avlak üye gideceğim dememiş miydin? (CGA: 76).

[2] Ф.Кутлу әсәрнең жанрын роман дип күрсәтә, татар әдәбият белемендә ул повесть буларак тикшерелә.

Аксыргакның атаклы Сабан туен мәңгеләштерергә килә! (ҖКК: 342) / Aksırgak'ın meşhur Saban Toyu'nu ölümsüzleştirmek için geliyor! (CGA: 178).

Галимә «Cuma günü, akşam...» әсәреннән төрек мәдәниятендә булмаган, татар халкының көнитеше, этнографиясе белән бәйле этномәдәният лексемаларын транскрипция аша бирү мисалларын да терки: Шикәр сипкән дөге бәлешен үлеп ярата Бибинур, бер башы гына булгач, бәлешне сандугач оясы хәтле итеп кенә пешерә (ҖКК: 232) / Üzerine şeker serpilmiş pirinç belişini ne sever Bibinur. Bir başına olduğundan belişi bülbül yuvası kadarcık yapardı (CGA: 51) [Хабибуллина, с. 63-64].

«Җомга көн, кич белән» повестеның төрек теленә тәрҗемәсендә дә образлылык тудыру ысулларыннан берничә төрнең кулланылышы күзәтелә. Беренче чиратта, укучы әсәрне төгәл, мәгънәви тәрҗемә итү ысулының нәтиҗәсен күреп соклана. Ф.Кутлуның тәрҗемәдә А. Гыйләҗев теленә сакчыл карашы, язучының эмоциональ һәм тәэсирле татар тел байлыгыннан киң файдаланганлыгын тоемлавы сиземләнә: «*Тау башында җил иде, башак исен сеңдергән җил...*» [Гыйләҗев, 1982: 84] җөмләсе «*Tepe rüzgarliydi olgunlaşmaya yüz tutmuş başak kokusunu sindiren rüzgar ...*» [Giylecev, 2013: 33] дип тәрҗемә ителгән. Ф. Кутлу «*башак*» сүзен төрекчәдә «*өлгерергә җитешкән башак исен сеңдергән җил*» аңлатмасы аша биргән. «*Тегәрҗеп авылына күбәләк канаты кебек үтә күренмәле җаны гына ияреп килгәндер?*» [Гыйләҗев, 1982: 86] җөмләсендә «*күбәләк канаты кебек*» чагыштыруы исә сүзгә-сүз тәрҗемә ителгән – «*Tigercip Köyü'ne kelebek kanadı gibi şeffaf ruhu gelmiştir belki?*». [Giylecev, 2013: 35]

Тропларның аерым компонентларын үзгәртеп тәрҗемә итү ысулы да очрый. Мәсәлән, «*Диде дә, моңлы күзләрен тутырып карап, тынып калды*» җөмләсендә [Гыйләҗев, 1982: 80] «***моңлы күзләрен***» эпитеты «*hüzün dolu gözlerini*» (***сагыш тулы күзләрен***) [Giylecev, 2013: 29] дип, ә «*анысы да күңел аклыгыннан әйтелгән сүзләр ләбаса!*» җөмләсендә [Гыйләҗев, 1982: 83] «***күңел аклыгы***» метафорасының мәгънәсе беркадәр үзгәртеп тәрҗемә ителгән – «*saygısındandı*» (***хөрмәтеннән)*** [Giylecev, 2013: 33]. Автор оригиналында хикәяләүченең күңел халәте (*күңел аклыгыннан*) сурәтләнсә, тәрҗемәдә исә аның икенче кешегә мөнәсәбәте (*хөрмәтеннән* ) чагылыш таба. «*Мактанса да, күңел түрендә курку бар иде*» җөмләсендә [Гыйләҗев, 1982: 93] «*күңел түрендә*» метафорасы А. Гыйләҗевтәге мәгънә төсмере төгәл җиткерелмәгән «*içinde*» (*эчендә)* сүзе белән генә алыштырып бирелгән [Giylecev, 2013: 43].

Әсәрдә тәрҗемәче фразеологик әйтелмәләрне төрекчәдә булган әзер әйтелмәләр белән алыштыру ысулын да куллана. Мәсәлән, «*Бибинурның күзләре **кызыгып яна, хәтта авызына су килә,** шулай да бирешми*» [Гыйләҗев, 1982: 97] җөмләсендә фразеологизм телдәге әзер әйтелмә аша тәрҗемә ителгән: «*Görünce Bibinur'un **içi gider**, ağızının suyu akar, ama yine de belli etmezdi*» [Giylecev, 2013: 48].

«Cuma günü, akşam...» («Җомга көн, кич белән...») әсәрендә тропларны кыскартып яисә нейтральләштереп тәрҗемә итү сирәк булса да күзәтелә. Мисал өчен, «***Язгы көләч авыллар*** *өстенә көлеп караган ал кояш...*» [Гыйләҗев, 1982: 80] җөмләсендә «*авыллар*», «*көлеп караган ал кояш*» сүзтезмәсе – «*gülümseyen güneş» (көлемсерәгән кояш)* [Giylecev, 2013: 32] буларак тәрҗемә ителгән. «*Берәм-берәм **авыр, саллы йолдызлар** кабынды*» [Гыйләҗев, 1982: 87] берәмлегендә эпитет төшереп калдырылып, «yıldızlar» (*йолдызлар)* [Giylecev, 2013: 37] сүзе белән генә бирелгән. Әлбәттә, мондый очраклар күп булса, язучының поэтик теленең матурлыгын киметә, укучыга аның фикер тирәнлеген ачарга комачаулый.

Тәрҗемә текстында, киресенчә, аерымланган хәл кисәген җөмлә эченнән аерып чыгарып, мөстәкыйль берәмлек итеп бирү очраклары да күзәтелә. «*Караңгы булса да, череп укмашкан саламны әрсез җил иркенә бирмичә, түбә өстенә рәт-рәт тезелешеп яткан каен бастырмалар аермачык күренеп тора иде*» [Гыйләҗев, 1982: 77] җөмләсенең *череп укмашкан саламны әрсез җил иркенә бирмичә* өлеше аерым җөмлә калыбына салынган: «*Evin saman çöpleriyle örülü çatısını, keyfince esen rüzgar kendi haline bırakmıyordu.* ***Karanlık olmasına rağmen çatının üzerindeki sıra sıra huş gövdeleri farkedeliyordu***» [Giylecev, 2013: 25]. (*Караңгылык булуга карамастан, түбә өстендәге рәт-рәт каен гәүдәләре күренеп тора иде*). Ф.Кутлу аерым җөмләләрдәге сүзтезмәләрне төрек укучысына төшендерү нияте белән, аңлатып бирү ысулын файдалана: «Аксыргак авылының ... төньягында ***юаш таулар тезмәсе***, тау өстендә кара урман, урман артында яңа район башлана» [Гыйләҗев, 1982: 78] // «Aksırgak Köyü'nün güneyinde *sıra sıra yayvan* ***(рәт-рәт булып җәелгән)*** *tepeler*,

tepelerde yeşil orman ***(яшел урман)***, ormanın bitiminde ise yeni bir ilçe başlıyor» [Giylecev, 2013: 27]. Яки: «***Тотышыннан тирән кайгы*** кичерү бөркелеп тора иде [Гыйләҗев, 1982: 88] / Görünüşünden, tüm hal ve hareketlerinden ***(бөтен хәле һәм хәрәкәтләреннән)*** *derin bir kaygı* ***(тирән бер кайгы)*** çağlıyordu [Giylecev, 2013: 38]. «Бибинур вак-вак кына йота-йота итле ***ашны да ялтыратып куйды»*** [Гыйләҗев, 1982: 91] // «Küçük lokmalarla ***etli yemeği*** de bir güzel yedi [Giylecev, 2013: 41]. Ф.Кутлу «аш» сүзен «итле ризыклар» дип тәрҗемә иткән. Бу очракта, шөбһәсез, төрек телендә «аш» мәгнәсендәге «çorba» сүзен куллану мәгънә ягыннан дөрес булыр иде. «Bir güzel yedi», ягъни «матур итеп, әйбәтләп ашады» гыйбарәсен «ялтыратып куйды» тезмәсе аша бирү дә мәгънәгә зыян салган. Әлбәттә, тәрҗемә текстта сүз, гыйбарәләрне кыскартулар яки бөтенләй төшереп калдырулар, бер яктан, авторның укучыга җиткерергә теләгән фикерен, хис-тойгыларын, аерым мәгънә төсмерләрен ачуга комачауласа, икенче яктан, оригинал әсәр теленең матурлыгын ярлыландыра. Шунысы куанычлы: мондый очраклар тәрҗемәләрдә күп түгел. Сүзне йомгаклап, шуны әйтергә мөмкин: А.Гыйләҗев әсәрләренең төрек теленә тәрҗемәләре, нигездә, уңышлы, төрек укучысына татар халкы чынбарлыгын, көнкүрешен, милли психология үзенчәлекләрен ача. Татар телендәге гыйбарәләрнең, әдәби тропларның төрек телендә тәңгәл эквивалентлары булу телләребезнең якынлыгы һәм рухи-мәдәни кыйммәтләрнең уртаклыгы турында сөйли.

Билгеле булганча, «тәрҗемә әсәре башка тел шартларында мөстәкыйль сүз сәнгате әсәре буларак яши, һәм шул чикләрдә генә кабул ителә һәм бәяләнә ала» [Топер, с. 65]. Әлеге хезмәттә тәрҗемә эшчәнлеге өйрәнү объекты булып торган Ф. Кутлу иҗаты татар-төрек мәдәниятләрен нигытып, тугандаш халыкларның бер-берсе белән аңлашуына, әдәп-әхлаклөгать алмашуына юл, күпер сала. Ф. Кутлу әдәби тәрҗемәләре, бер яктан, милли сүз сәнгатенең эстетик казанышларнын ассызыклап, аны дөнья аренасына чыгарса, икенче яктан, башка милләт укучыларын татар халкының этник үзенчәлекләре, яшәеше һәм рухи кыйммәтләре белән дә таныштыра. Шуның белән халыклар арасында бәйләнешләр урнаштыру чараларыннан берсе булган әдәби тәрҗемләрнең мөмкинлекләрен яңарта һәм ныгыта.

**Әдәбият**


*Abdullah Tukay.* Şiirler / Габдулла Тукай: шигырьләр / тәрҗ. А. Акбаш, Ф. Кутлу. Анкара: "Бәнгү" нәшр., 2016. 224 б.

Altın Sincap / "Алтын тиен": Балалар өчен хикәяләр җынтыгы / тәрҗ. Ф. Кутлу. Анкара: "Бәнгү" нәшр., 2014. 293 б.

*Аристович П.А.* Сущность художественного перевода: автореф. дисс. ... канд. филол. н. Тбилиси, 1984. 25 с.

Beyaz Hırkalı İhtiyar / Зәйдулла Р. "Ак япанчалы карт" / тәрҗ. Ф.Кутлу. Анкара: "Бәнгү" нәшр., 2016. 111 б.

Vasiyet / "Васыять": повесть һәм хикәяләр җыентыгы / тәрҗ. Ф.Кутлу, Һ. Әрсой-Надир, Т. Арслан. Истамбул: "Замбак" нәшр., 2012. 111 б.

*Ганиева Р.К.* Творчество Габдуллы Тукая в контексте мировой литературы // Сайт "Габдулла Тукай" // URL: http://gabdullatukay.ru/news/gabdulla-tukaj-v-kontekste-mirovoj-literatury/

*Ганиева Р. К.* Шагыйрьнең рухи дөньясы (Габдулла Тукай энциклопедик сүзлек-белешмәсенә әзерләнгән материаллардан). Казан: ТаРИХ, 2002. 112 б.

*Гыйләҗев А.* Җомга көн, кич белән... Повестьлар. Казан: Татар. кит. нәшр., 1982. 360 б.

*Ğıylecev A.* Cuma günü, akşam… / Гыйләҗев А. "Җомга көн, кич белән..." / тәрҗ. Ф. Кутлу. Анкара "Бәнгү" нәшр., 2013. 202 б.

*Гыйләҗев А.* Сайланма әсәрләр. Биш томда. 1 том. Казан: Тат.кит. нәшр., 2002. 431 б.

*Ğıylecev A.* Bir Avuç Toprak / Гыйләҗев А. Өч аршын җир) / тәрҗ. Ф. Кутлу. Анкара: "Бәнгү" нәшр., 2013. 113 б.

"Изге эш башкару – үзе бәхет" / Л. Галимҗанованың Ф.Кутлу белән интервьюсы // Шәһри Казан // URL: http://www.sptatar.ru/index.php?option=com_k2&view=item&id=310: фатих-кутлу-"изге-эш-башкару-–-үзе-бәхет"&lang=tt.

*Күпрелезадә (Мөхәммәд Фуат).* Габдулла Тукаев // Казан утлары. 2009. №4. Б. 115-124 (төрекчәдән Н.Вахитов тәрҗемәсендә).

*Маллалиев Г.Н.* Проблемы художественного перевода поэзии (на материале поэтических текстов русской и табасаранской литератур): автореф. дисс. ... канд. филол. н. Махачкала, 2006. 24 с.

Mavi Hüzün / "Зәңгәр сагыш": Разил Вәлиев шигырьләре / тәрҗ. Ф. Кутлу, Һ. Ташкын. Истанбул: "Да" нәшр., 2007. 144 б.

*Миңнегулов Х.Ю.* Татарга да тылмач кирәк // Мәдәни җомга. 2008 10 октябрь.

*Мөхәммәтов И.Р.* Татар-төрек әдәби багланышларында Мөхәммәд Чәләбинең "Мөхәммәдия" китабы. Казан: ТФАнең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты, 2007. 136 б.

*Нагимов Н.И.* Переводы Сагита Сунчелея из западноевропейской литературы: автореф. дисс. ... канд. филол. н. Казань, 2006. 23 с.

*Нурмөхәммәтова Р.С.* Татар теленең этномәдәният лексикасы // TATARICA. 2016. №1 (6). Б.34-42.

*Рахман Рифә.* Төрек-татар әдәби бәйләнешләренең кайбер сәхифәләре // Казан утлары. 2002. № 7. Б. 66-72.

*Рахманов З.А.* Проблемы художественного перевода и литературных связей: автореф. дисс. ... канд. филол. н. Душанбе, 1991. 24 с.

*Сайфулина Ф.С.* Татарско-турецкие культурные и научные взаимосвязи: история и современность // Филология и культура. Philology and Culture. 2014. №2 (36). С.322-326.

*Сафина Г.Ф.* Лирика А.С. Пушкина в переводах на татарский язык: история и поэтика: автореф. дисс. ... канд. филол. наук. Казань, 2014. 23 с.

Sessiz Kuray / Тавышсыз курай: повесть һәм хикәяләр җыентыгы / тәрҗ. Ф. Кутлу. Анкара: “Бәнгү” нәшр., 2013. 190 б.

Төрек матбугатында “Өч аршын җир” турында басылып чыккан әдәби тәнкыйть мәкаләләре // URL: http://www.sptatar.ru/index.php?option=com_k2&view=item&id=314: төрек-матбугатында-“өч-аршын-җир”-турында-басылып-чыккан-әдәби-тәнкыйть-мәкаләләре&lang=tt (дата обращения 12.06.2017).

*Топер П.* Перевод и литература: творческая личность переводчика // Вопросы литературы. 1998. №6. С.61-65.

*Хабибуллина Э.К.* Языковые трансформации при переводе татарской литературы на турецкий язык: дис. ... канд. филол.н. Казань: КФУ, 2016. 283 с.

*Хабутдинова М.М.* Из истории текста повести А.М. Гилязова «Җомга көн, кич белән...» (“В пятницу, вечером...”) (1979) // Филология и культура. Philology and Culture. 2012. №3(29) (2012). С.156-164.

*Ханнанов Р.* Төрек-татар әдәби бәйләнешләре (Турецко-татарские литературные связи) // Казан утлары. 2011. № 2. Б.78-83.

*Харрасова Р.* Әдәби бәйләнешләр яктылыгында. Казан: «РПФ «Гарт», 2002. 138 б.

Cengâver Alp’in Kahramanlıkları / Батулла Р. “Алып батыр маҗаралары” / тәрҗ. Ф. Кутлу. Анкара: “Бәнгү” нәшр., 2013. 178 б.

Fildişi Çakı / “Сөяк саплы пәке”: Балалар хикәяләре җыентыгы / тәрҗ. Ф. Кутлу. Анкара: “Бәнгү” нәшр., 2013. 168 б.

# ФАТИХ КУТЛУ КАК ПЕРЕВОДЧИК И ПРОПАГАНДИСТ ТАТАРСКОЙ ЛИТЕРАТУРЫ В ТУРЦИИ

**Флера Сагитовна Сайфулина,**
Казанский федеральный университет,
Россия, 420008, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 18,
fsaifulina@mail.ru.

**Альбина Зинфировна Валиева,**
Национальный исследовательский университет
«Высшая школа экономики»,
Россия, 101000, г. Москва, ул. Мясницкая, д. 20,
fsaifulina@mail.ru.

В статье систематизирован материал по истории изучения татарско-турецких литературных взаимосвязей и дан краткий обзор переводов, сделанных в начале XXI века. Работа нацелена на изучение огромного вклада, который внес своей переводческой деятельностью в пропаганду татарской литературы в Турции переводчик, член Союза писателей РТ, филолог Фатих Кутлу. Как известно, в этом направлении начиная с 1985 года наблюдался спад. Взор переводчика Ф. Кутлу прикован к известным произведениям татарской литературы разных периодов и жанров: он познакомил турецкого читателя с произведениями классиков татарской литературы XX века, таких как Г. Тукай, Ф. Амирхан, Г. Ибрагимов, Ш. Камал, А. Еники, а также с творениями современных авторов – Р. Валиева, М. Галиева, Г. Гильманова, Р. Зайдуллы и др.

Особое внимание турецкий переводчик уделяет произведениям известного прозаика и драматурга А. М. Гилязова. Ф. Кутлу заинтересовался творчеством этого самобытного писателя неслучайно, так как в его произведениях ярко раскрывается своеобразие татарского национального характера, особенности миросозерцания и мироощущения жителя татарской деревни. Ф. Кутлу перевел на турецкий язык повести А. М. Гилязова «Три аршина земли» и «В пятницу, вечером...», которые послужили материалом для исследования в данной статье:

дается оценка переводу этих произведений, отмечается мастерство переводчика, умение передать национальное и художественное своеобразие текстов А. М. Гилязова.

**Ключевые слова**: татарская литература, татарско-турецкие литературные связи, литературное наследие, культура, татарские писатели, Аяз Гилязов, литературный перевод, Фатих Кутлу, средства образности.